ПӘНҖЕШӘМБЕ
25 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 19 (5819)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: *Казан, Матбугат йорты.* ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы карарларын массага

ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумы гаять әһәмиятле политик мәсьәләләрне тикшереп хәл итте. Пленум „1939 нчы елны партиянең Татарстан оешмасы буенча ВКП(б) га кабул итүнең йомгаклары турында“ ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Гафиятуллин докладын һәм „1940 нчы елның язгы чәчүенә хәзерлек турында“ ТАССР Халык Комиссарлары Советы председателе иптәш Тынчеров докладын тыңлады һәм бу мәсьәләләр буенча махсус карарлар кабул итте.

Узган чор эчендә һәм бигрәк тә, ВКП(б) ның тарихи XVIII нче съезды карарларыннан соң партиянең Татарстан оешмасы үзенең сафларын оешу ягыннан тагын да ныгытты, хезмәт ияләре белән үзенең элемтәсен күп тапкырлар көчәйтте. Масса - оештыру эшләре һәм политик - агитация эшләре киң колач алдылар. Болар партия оешмасының авторитетын тагын да югарырак күтәрделәр, хезмәт ияләре тарафыннан аңа карата булган ышанычны тагын да ныгыттылар. Шушы эшләрнең нәтиҗәсе буларак, 1939 нчы елда партия оешмасының сафлары 57,4 процентка үсте.

ВКП(б) сафларына республикабызның иң алдынгы кешеләре — стахановчы эшчеләр, колхозчылар, инженер-техник работниклар, укытучылар, агрономнар, врачлар, сәнгат эшлеклеләре кабул ителделәр. Партия сафларын үстерү эше ВКП(б) га яңа кабул ителгәннәрне идея ягыннан коралландыру белән, аларны практик эш өстендә чыныктыру белән бергә бәйләп алып барылды. Үзләренең политик һәм гомуми белем дәрәҗәләрен күтәрү өстендә тырышып эшләүче, җәмагат эшләренә актив катнашучы яшь коммунистлар җитәкче эшләргә кыю рәвештә күтәрелделәр. 1939 нчы елның икенче яртысында район күләмендә һәм түбәнге җитәкче эшкә күтәрелгән коммунистларның 30 проценты ВКП(б) сафларына үткән елны гына кабул ителгән кешеләр булу моны бик ачык күрсәтә.

Шуның белән бергә, ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы эшнең бу өлкәсендә зур гына җитешсезлекләр яшәп килүен дә күрсәтеп үтте. Партия сафларына яңа членнар кабул итү өлкәсендә төп җитешсезлек шуннан гыйбарәт ки, ВКП(б) ның кайбер башлангыч оешмалары партия сафларын үстерү мәсьәләсендә төп принципны онтып, сан артыннан кууга биреләләр. Бу кимчелек Саба, Чистай Югары Ослан, Кызыл Йолдыз, Аксубай, Дөбъяз һәм Теләче районнарындагы башлангыч партоешмаларда да аеруча күзгә бәрелә.

ВКП(б) га яңа членнар кабул иткәндә төп принцип итеп партия составының сыйфаты мәсьәләсе куелырга тиеш. Безнең партиябез өчен аның членнарының саны түгел, бәлки сыйфаты әһәмиятле икәнлекне бер генә минутка да истән чыгармаска, ВКП(б) га яңа членнар һәм кандидатлар кабул иткәндә төп игтибарны аларның сыйфатына юнәлдерергә кирәк. ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм иптәш Сталин безне партия сафларының чисталыгы һәм ныклыгы өчен армыйталмый көрәшергә чакыралар. Партия оешмалары бу таләпне тулы һәм төгәл үтәргә тиешләр.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы партоешмаларның үсүен регулярлаштерүнең булмавын, шуның нәтиҗәсендә шәһәрнең һәм авылның төп профессия работникларын партиягә тартуның начар булуын аеруча күрсәтеп үтте. Шуның белән бергә, пленум, ВКП(б) сафларына кабул ителүчеләр арасында хатын-кызлар процентының бик түбән булуын (17,3 процент), стажлары үткән кандидатлар саны шактый күп (3.674 кеше) булуын күрсәтте һәм партоешмалардан бу җитешсезлекләрне бик тизлек белән бетерүне таләп итте.

1940 нчы елгы язгы чәчүгә хәзерлек турында пленум тарафыннан кабул ителгән карар зур политик әһәмияткә ия булып тора. Пленум тарафыннан билгеләнгән чаралар—алар 1940 нчы елның язгы чәчүенә үрнәк рәвештә хәзерләнүне тәэмин итүгә, колхозларда, совхозларда иген уңышын тагын да күтәрүгә юнәлдерелгәннәр. Пленумның бу карары һәрбер колхозда, бригадада, звенода ныклап өйрәнелергә, колхоз правлениеләре аны көндәлек эшкә программ кулланма итеп кабул итәргә тиешләр.

Язгы чәчүне уңышлы үткәрүдә авыл хуҗалыгы машиналары зур урын тоталар. Пленум бу мәсьәләгә җидди әһәмият бирде һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны төгәлләүнең конкрет срокларын билгеләде. Пленум карарында болай диелә: „МТС ларда һәм совхозларда тракторларга һәм тагылма инвентарьга ремонт ясауны 1940 нчы елның 25 нче февраленә һәм колхозларда гади машиналарга (чәчү машиналарына, сабаннарга, тырмаларга һ. б.) ремонт ясауны 20 нче мартка тәмам итәргә“.

Күрәсез, срок озын түгел. Ә МТС ларда һәм совхозларда ремонт эшләре ничек бара соң? Большевистик ачыклык белән әйтергә кирәк: гафу ителмәслек начар бара. Шушы елның 15 нче гыйнварына МТС лардагы тракторларның бары 35,6 процентына гына ремонт ясалу моны ачык күрсәтә. Нөркәй, Тымытык, Теләче, Кама Тамагы МТС лары тракторларга ремонт ясау эшләрен уңышлы рәвештә төгәлләгән вакытта, күпчелек МТС ларның гафу ителмәслек артта баруларын нәрсә белән аңлатырга? Моны, бары тик, МТС лар эшенә ТАССР Наркомземының, район башкарма комитетларының һәм ВКП(б) райкомнарының җитәкчелек итүләре йомшару белән генә аңлатырга мөмкин. ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы, машина-трактор станцияләренә карата моңа кадәр яшәп килгән игтибарсызлыкны бик тизлек белән бетерергә, МТС ларга оператив җитәкчелек һәм конкрет булышлык булдырырга такдим итте. Пленум тарафыннан билгеләнгән чаралар тулысынча үтәлергә тиешләр.

ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумы партиянең Татарстан оешмасы сафларын республикабызның алдынгы кешеләре исәбенә туктаусыз үстерү буенча, 1940 нчы елгы язгы чәчү эшләренә хәзерлек һәм аны уңышлы үткәрү буенча ачык һәм конкрет күрсәтмәләр бирде. Партия оешмаларының бурычы—пленум карарларын барлык партиялеләр массасына җиткерүдән, комсомолецлар һәм партиясез актив арасында пленум карарларын ныклап өйрәнүне оештырудан, аны үтәү көрәшенә барлык партиялеләр һәм партиясезләр массасын туплаудан гыйбарәт.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАЛАРЫ

21 нче гыйнварда фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады. Барлык юнәлешләрдә разведчикларның эзләнүләре, урны-урны белән артиллерия атышуы.

Безнең авиация разведка очышлары һәм хәрби очышлар үткәрде.

⁂

22 нче гыйнварда барлык юнәлешләрдә разведка частьләренең кечкенә күләмдәге бәрелешләре булды, күп кенә районнарда артиллерия атышуы булды.

Безнең авиация разведка очышлары үткәрде.

⁂

23 нче гыйнварда **Ухта** һәм Реболы юнәлешләрендә разведчикларның эзләнүләре. **Петрозаводск** юнәлешендә аерым пехота отрядларының хәрби хәрәкәтләре. **Карелия** бугазында артиллерия атышуы һәм разведчикларның эзләнүләре.

Безнең авиация разведка очышлары һәм хәрби очышлар үткәрде.

МОСКВАДА ЛЕНИН КӨННӘРЕ

ЛЕНИН МАВЗОЛЕЕ ЯНЫНДА

Ленин көннәрендә Кызыл Мәйданга В. И. Ленин мавзолеена хезмәт ияләре өзлексез рәвештә агылдылар. Эшчеләр, колхозчылар, белгечләр, хезмәткәрләр, Кызыл Армия сугышчылары, командирлары һәм политработниклары, студентлар, балалар—төрле яштәге, күп төрле милләттәге һәм профессиядәге кешеләр бергә бөек Ленинне хөрмәтләп искә алу өчен килделәр.

Ленин көннәрендә Мавзолейдә ун меңнәрчә хезмәт ияләре булды. 22 нче гыйнварда гына да Лениннең гробы яныннан 24 меңнән артык кеше үтте.

БАШКАЛА МУЗЕЙЛӘРЕНДӘ

Ленин көннәрендә В. И. Ленин Үзәк Музее залларында гаять җанлы булды. Меңнәрчә москвалылар һәм экскурсиячеләр биредә, Владимир Ильич Лениннең һәм аның эшен дәвам иттерүче бөек Сталинның тормышын һәм эшләрен чагылдырган күп сандагы экспонатлар белән нык кызыксынып таныштылар.

22 һәм 23 нче гыйнварда Революция музеенда 5 меңнән артык хезмәт иясе булды.

Москва хәрби округы частьләренең бик күп сугышчылары, командирлары һәм политработниклары кичә һәм өченче көн Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең Үзәк музеенда булдылар һәм анда „Ленин, Сталин һәм Кызыл Армия“ дигән темага куелган материаллар белән таныштылар.

В. И. ЛЕНИН МУЗЕЕНЕҢ ЛЕНИНГРАД ФИЛИАЛЫНДА

ЛЕНИНГРАД, 23 гыйнвар. (ТАСС). В. И. Ленин музееның Ленинград филиалына керә торган урында кечкенә күпер ясалып куелган. Аңарга тарихи броневик ясалган. 1917 нче елның 16 нчы апрелендә эмиграциядән кайткан көнне үзен каршылаучы меңнәрчә эшчеләр алдында Ленин шул броневикка басып речь сөйләгән иде.

Кичә шушы атаклы броневик янында зур митинг булды. Митингта Финляндия вокзалы мәйданы янында Ильичне каршылауда катнашучы иптәш Ф. А. Быков (1917 нче елны броне-отрядта солдатлар комитетының элекке председателе), иптәш Д. И. Черкашин һәм башкалар речьләр сөйләделәр.

В. И. ЛЕНИН ҮЛҮГӘ XVI ел

ЗУР ТЕАТРДА ТАНТАНАЛЫ—ТРАУР УТЫРЫШЫ

Зур театрның фронтонында—ал байраклар, ә колонналар арасында көчле якты булып бөтен хезмәт иясе кешелек дөньясына таныш булган

Ленин сүзе балкый.

Театр залына башкала хезмәт ияләренең вәкилләре — эшчеләр, инженерлар, галимнәр, Кызыл Армиянең сугышчылары һәм командирлары, партия, совет, комсомол работниклары тулганнан тула бара. Бергә илебезнең атаклы бик күп кешеләре—Советлар Союзы геройлары, орденлылар килгәннәр. Алар революция даһиен, большевиклар партиясенә нигез салучыны, Совет дәүләтен төзүчене—В. И. Ленинне хөрмәтләп искә алу өчен җыелганнар.

Залда тантаналы күрнеш. 1924 нче елның кайгылы көннәрендә биредә иптәш Сталин тарафыннан бирелгән бөек антның сүзләре яңгырады. Ул вакыттан бирле 16 ел үтте. Ант үтәлде. Бу еллар эчендә иптәш Сталин җитәкчелегендә партия гаять бөек көрәш һәм җиңүләр юлын үтте.

...Пәрдә күтәрелә. Сәхнә түрендә В. И. Лениннең кызыл бархыт белән әйләндерелеп алынган гаять зур портреты. Тавышсыз гына почетлы караул алмашынып тора.

18 сәгат 50 минутта сәхнәдә И. В. Сталин, В. М. Молотов, Л. М. Каганович, К. Е. Ворошилов, М. И. Калинин, А. А. Андреев, А. И. Микоян, Л. П. Берия, Н. М. Шверник, Г. М. Маленков, Н. А. Булганин, А. С. Щербаков, М. Ф. Шкирятов, Г. М. Димитров, С. М. Буденный, А. Е. Бадаев, Е. М. Ярославский, В. П. Пронин һәм башкалар күренәләр. Залдагылар ВКП(б) ның Ленинче-Сталинчы Үзәк Комитетын, Лениннең васиятләрен турылыклы саклаучы һәм аның эшен бөек дәвам иттерүче иптәш Сталинны урыннарыннан торып котлыйлар. Халыкларның бөек юлбашчысына бөтен халыкның кайнар мәхәббәте яңгырый.

Иптәш Калинин, траур утырышын ачып, кыскача кереш речь сөйли. Ул ленинизмның мәңгелек булуы турында, хезмәт ияләренә Ленин тарафыннан калдырылган һәм иптәш Сталин тарафыннан даһиларча үстерелгән һәм үстерелә торган бу бөек таглимат турында, аның һәр нәрсәне җиңүче таглимат булуы турында сөйли.

Залда утыручылар, иптәш Калинин такдиме буенча, В. И. Ленинне урыннарыннан торып искә алалар. Траур маршы яңгырый.

ВКП(б) ның Москва Өлкә Комитеты һәм Москва Шәһәр Комитеты секретаре иптәш Щербаков доклад өчен сүз ала.

Утырыштан соң В. И. Ленинне искә алуга багышланган концерт булды. Концертта башкаланың күренекле сәнгат мастерлары катнашты. (ТАСС).

Советлар иле Владимир Ильич Ленинне хөрмәтләп искә ала

183 миллионлы совет халкы сөекле Ильичне хөрмәтләп искә ала.

21 нче гыйнварда бик күп шәһәрләрдә һәм авылларда Владимир Ильичкә памятниклар ачылды.

ТАШКЕНТ. Бохара өлкәсенең һәм уңышны иң яхшы бирә торган Ферганә үзәнлегенең таулы кышлакларында, орденлы Үзбәкстанның барлык шәһәрләрендә һәм авылларында В. И. Ленин истәлегенә багышлап, тантаналы-траур җыелышлары булды. Большевиклар партиясен барлыкка китерүче, эшче һәм крестьяннарнең дөньяда беренче социалистик дәүләтен оештыручы В. И. Лениннең тормышы турында меңнәрчә агитаторлар һәм докладчылар хезмәт ияләренә сөйләделәр.

АЛМА-АТА. Культура сараенда В. И. Ленинне искә алуга багышлап бөтен шәһәр күләмендә тантаналы-траур утырышы булды. Казагстанның академик драма театры Погодинның „Мылтыклы кеше“ дигән пьесасын казак телендә беренче тапкыр күрсәтте.

СТАЛИНАБАД. Сталин исемендәге Зур Ферганә каналын төзүче меңнәрчә кешеләр берничә көн мактаулы Ленин вахтасында тордылар.

Памирда, көчле рәвештә ага торган Пәнҗ елгасы ярлары буенда батыр пограничниклар, сөекле Ватанның изге чикләрен сизгер рәвештә саклаган хәлдә, мактаулы Ленин вахтасында тордылар.

ЕРЕВАН. 21 нче гыйнварда, Әрмәнстанның Зангибасар районындагы Гейгумбед авылында яңа клуб ачылды. Кич белән клубта „Ленин Октябрьдә“ дигән кинофильм күрсәтелде. Микоян районының Арпа авылында, Ашнак, Дзитанков, Мастера, Югары Талин авылларында В. И. Ленингә памятниклар ачылды.

ЛЕНИНГРАД. 22 нче гыйнварда иртәдән алып ук „9 нчы гыйнвар корбаннары“ каберлегенә, „Канлы якшәмбе“ көнендә һәлак булганнарны искә алу өчен, традицион митингка йөзләрчә кешеләр юнәлде. 1905 нче ел революциясендә катнашучылардан Николаева, Балунов, Яковлев, Шабанова иптәшләр митингта речьләр сөйләделәр.

Тбилисидә, Магнитогорскийда, Благовещенскийда, Орелда, Вологдада, Архангельскийда, Ростов-Донда, Винницада, Пермьдә, Торнопольда, Дрогобычта һәм Советлар Союзының башка бик күп шәһәрләрендә партия, совет һәм профсоюз оешмаларының Владимир Ильич Ленинне искә алуга багышланган тантаналы-траур җыелышлары булды. (ТАСС).

АКШ ТА ЛЕНИН ИСТӘЛЕКЛӘРЕНӘ КҮП МЕҢЛЕ МИТИНГ

НЬЮ ЙОРК, 22 гыйнвар. (ТАСС). „Дейли Уоркер“ газетасы Детройтта Владимир Ильич Ленин истәлегенә багышланып җыелган митингта 1.500 кеше булганлыкны хәбәр итә. Митингтагылар үзләренең резолюцияләрендә АКШ ны сугышка тартуга каршы көрәшергә вагдә биргәннәр.

Бостонда һәм Кливлендта да шундый ук митинглар булган.

НЬЮ-ЙОРК, 23 гыйнвар (ТАСС). Кичә кич белән Нью-Йоркның иң зур залларыннан берсе „Мэдисон Сквер Гарден“ залында Ленин истәлекләренә багышланган митинг булды. Митингда 20 мең кеше катнашты. Зал шыгырым тулган иде, һәм берничә мең кеше митингка керә алмады.

Америка компартиясе секретаре Браудер зур речь белән чыкты. Браудер үзенең речендә болай диде: „Ленин үлмәде—ул үзенең бөек шәкертендә һәм эшен дәвам иттерүчедә—Сталинда яши, Сталин Советлар Союзын социализмга алып килде. Тынычлык өчен, империалистик сугышка каршы барлык илләрнең халыклары көрәшенә Сталин җитәкчелек итә“.

Аннары Браудер, эшчеләр сыйнфы файдасы эше өчен үзенә булган хөкем карарын горурлык белән тыңлаганлыгын күрсәтеп үтте. Миңа каршы оештырылган процесс, диде ул, өстен сыйныфның Америка халкын сугышка тартуга юнәлдерелгән политикасында бер эпизод кына булып тора. Хөкүмәт социаль закончылыкны юкка чыгарып һәм АКШ ны империалистик сугышка тарту өчен база хәзерләп, реакциянең басымына юл куйды. Хөкүмәт шулай ук компартиягә һәм аның җитәкчеләренә каршы поход башлауны таләп итүдә реакцион элементларга юл куйды, чөнки компартия сугышка каршы көрәшнең беренче сафларында тора. Бүген тәмам була торган суд процессы бөтен эшчләр хәрәкәтенә каршы удар булып тора, чөнки ул эшчеләрнең хокукларын яклаучы һәм сугышка каршы көрәшүче барлык прогрессив элементларга каршы реакцияне яңа чыгышларга рухландыра. Компартия, диде Браудер, сугышка каршы, эшчеләр сыйнфының интересларын яклау өчен көрәшне дәвам иттерер.

Митингда катнашучылар резолюция кабул иттеләр, алар бу резолюциядә Браудер өстеннән суд приговорын алып ташлауны таләп иттеләр.

ЛЕНИН ҮЛҮГӘ 16 ЕЛ ТУЛУ ТУРЫНДА „СИНЬХУАЖИБАО“ ГАЗЕТАСЫ

ЧУНЦИН, 22 гыйнвар. (ТАСС). „Синьхуажибао“ газетасының 21 нче гыйнвар номеры Ленин үлүгә 16 ел тулуга багышланган. Газета үзенең баш мәкаләсендә болай яза: „Ленин җитәкчелеге астында Октябрь революциясе булды. Социализм Төзелешенең нигезе салынды. Ленин үлгәннән соң 16 ел эчендә, Лениннең эшен дәвам иттерүче һәм аның дусы—Сталин Лениннең таглиматын һәм васиятләрен тормышка үткәрә“.

В. И. ЛЕНИН МУЗЕЙ-ЙОРТЫНДА

Ленин көннәрендә Казандагы В. И. Ленин музей-йортына йөзләрчә экскурсант килде. Моннан 52 ел элек хезмәт ияләренең даһи юлбашчысы һәм остазы яшәгән бүлмәне Кызыл Армия сугышчылары һәм командирлары, Серго Орджоникидзе заводы эшчеләре, врачларның белемнәрен күтәрү курсларының укучылары, студентлар, йорт хозяйкалары, мәктәп балалары, пионерлар һәм башкалар карадылар. 21 нче гыйнвардан 23 нче гыйнварга кадәр музей-йортта 1.100 кеше булды.

21 нче гыйнварда бу йорттан В. И. Ленингә багышланган радио-тапшыру булды. Тапшыруда ТАССР ның халык артисты Ардаров һәм ТАССР ның атказанган артисты Сәлимҗанов иптәшләр катнаштылар.

„Союзкинохроника“ның Казан студиясе операторлары киножурналның чираттагы номеры өчен врачларның В. И. Ленин йорты музеенә килүләрен төшереп алдылар.

(ТатТАСС).

ТАТАРСТАН РАЙОННАРЫНДА ЛЕНИН КӨННӘРЕ

(ТатТАСС хәбәрләре буенча)

ТӘКӘНЕШ РАЙОНЫ

В. И. Лениннең тормышына һәм эшенә багышлап 21 нче гыйнварда Тәкәнештә партия, совет, профсоюз һәм комсомол оешмаларының һәм колхозчыларның кайгы утырышы булды. Утырышта 250 кеше катнашты.

Утырышта ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Закиров „Лениннән башка, иптәш Сталин җитәкчелегендә Ленин юлы буйлап 16 ел“ дигән темада доклад ясады.

Кайгы җыелышлары шулай ук Лубиян урман техникумында, Нырты совхозында, „Крестьянин“ такта яру заводында һәм районның барлык 86 колхозында булды.

БАУЛЫ РАЙОНЫ

Халыкларның бөек юлбашчысы В. И. Ленин үлүнең 16 еллыгы көнендә Баулы авылының җәмагат биналарына һәм колхозчылар йортларына кайгы флаглары эленде. Район клубында район үзәге хезмәт ияләренең кайгы җыелышы булды. Җыелышта „Лениннән башка, иптәш Сталин җитәкчелегендә Ленин юлы буйлап 16 ел“ дигән темада доклад ясалды.

Кайгы җыелышлары шулай ук районның 43 колхозында да булды.

ӘЛМӘТ РАЙОНЫ

Әлмәт районы хезмәт ияләре Владимир Ильич Лениннең үлүенә 16 ел тулуны киң күләмдә искә алып үттеләр. 21 нче гыйнварда кич белән Культура йортында район үзәге хезмәт ияләренең кайгы җыелышы булды. Җыелышта ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Саттаров „Лениннән башка, иптәш Сталин җитәкчелегендә Ленин юлы буйлап 16 ел“ дигән темада доклад ясады. Хезмәт ияләренең бөек Ленин истәлегенә багышланган кайгы җыелышлары районның барлык колхозларында да булды.

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ

В. И. Лениннең үлүенә 16 ел тулуга багышлап 21 нче гыйнварда район клубында, тимер юлчылар клубында һәм Октябрь районының барлык колхозларында кайгы җыелышлары булды. Район үзәгендә булган җыелышта ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Чекалин доклад ясады. Докладчы совет халкының большевиклар партиясе җитәкчелегендә, сөекле юлбашчыбыз һәм остазыбыз иптәш Сталин җитәкчелегендә социализмның илебездә ирешелгән гаять зур җиңүләре турында сөйләде.

АКТАШ РАЙОНЫ

ВКП(б) ның Акташ райкомының 57 агитаторы һәм пропагандисты Владимир Ильич Лениннең тормышы һәм эше турында районның колхозларында докладлар һәм беседалар үткәрделәр. Лениннең үлүенә 16 ел тулу уңае белән 21 нче гыйнварда Акташта кайгы җыелышы булды. Җыелышта 360 кеше катнашты.

АПАС РАЙОНЫ

21 нче гыйнварда Апас районының Югары Ындырчы авыл советы, „Тырышчы“ колхозы клубында авыл советының кайгы утырышы булды. Утырышта 148 колхозчы катнашты. „Лениннән башка, иптәш Сталин җитәкчелегендә Ленин юлы буйлап 16 ел“ дигән темадагы доклдтан соң колхозчылар коммунистлар партиясенең Линин васиятләрен тормышка ашырып колхозчыларның көнкүреш хәлен көннән-көн яхшырта баруын, культура үсеше турында кайгыртучанлык күрсәтүен сөйләделәр.

Колхозның шоферы, Халхын Гол елгасы районындагы сугышларда катнашкан иптәш Әмирханов үзенең речендә болай диде: „Хәзер безнең колхозчыларыбыз культуралы һәм таза тормышта яшиләр, безнең колхозда бер генә укый-яза белмәүче дә юк. Мондый бәхетле тормышны безгә бөтен дөнья хезмәт ияләренең бөек юлбашчылары Ленин һәм Сталин иптәшләр бирделәр“.

КОММУНИЗМ ӨЧЕН ЯЛКЫНЛЫ КӨРӘШЧЕ

(В. В. КУЙБЫШЕВНЫҢ ҮЛҮЕНӘ 5 ЕЛ ТУЛУГА КАРАТА)

Мочнан 5 ел элек, 1935 нче елның 25 нче гыйнварында партия, эшчеләр сыйнфы гүзәл пролетар революционерны, гражданнар сугышының талантлы полководецын, күренекле дәүләт эшлеклесен, Лениннең һәм Сталинның турылыклы шәкертен һәм көрәштәшен — Валериан Владимирович Куйбышевны югалттылар.

Куйбышев 47 нче яшендә үлде. Бу авыр югалту уңае белән халыкның кайгысы чиксез иде.

Куйбышевның һәлак булуы турындагы коточкыч дәреслек өч елдан соң ачылгач, аның үлеме—империалистик буржуазиянең троцкичы - бухаринчы ялчыларының мәкерле җинаятчел заговорларының нәтиҗәсе икәнлеге беленгәч, шушы ерткычлар бандасының Куйбышевны системалы рәвештә акрынлап үтерә барганлыклары һәм аны кабергә илтеп керткәнлекләре беленгәч,—халыкның кайгысы өстенә тагын үтерүчеләргә карата нәфрәт һәм ачу өстәлде.

Куйбышевны үтерүчеләрнең исемнәре мәңгелек хурлыкка капланды.

Куйбышев исме халыкның хәтерендә мәңге яшәр, яхшылык һәм рух ягыннан кристал кебек сафлык үрнәге булып, халык эшенә, социалистик революция эшенә куркусыз һәм үз-үзен аямыйча хезмәт итү үрнәге булып киләчәк буыннарга хезмәт итәр.

В. В. Куйбышев үзләренең революцион эшләрен революцион подпольенең авыр шартларында башлаган карт большевикларның данлыклы отрядыннан иде.

Караңгы царизм елларында профессионал- революционер булу өчен гадәттән тыш сыйфатлар: батырлык һәм тотанаклылык, ныклы омтылыш, политик максат юнәлеше, һәр төрле корбаннарга хәзер тору, социалистик стройның җиңүенә ныклы ышаныч булу кирәк иде.

В. В. Куйбышевта бу сыйфатлар барсы да тулысы белән бәр иде. Ул яштән үк семьясеннән китә, үзенең тормышын авыр сынауларга, мәхрумлекләр белән тулган, подпольече—революционер эшенә бирә. Патша жандармнары һәм полиция этләре аны эзәрлеклиләр, төрмәдән сөргенгә, сөргеннән төрмәгә куып йөртәләр, богаулыйлар, этаплап озаталар, ләкин Куйбышевның революцион омтылышын бер нәрсә дә сындыра алмады.

Куйбышев сигез тапкыр кулга алына, дүрт тапкыр сөргендә була. Төрмә һәм сөрген — Куйбышевның „университетлары" әнә шулар. Аның омтылышы әнә шунда чыныкты, революцион юлбашчы һәм оештыручы булуның гаять бай практик тәҗрибәсен ул шунда алды, массаны оештыру осталыгына ул шунда өйрәнде.

Пролетар революциясенең башка юлбашчылары кебек үк, Куйбышев та үзенең революцион юлын яшрен марксистик түгәрәкләрдән башлый. 14 яшендә чагында, кадетский корпус укучысы булган чагында, ул революцион оешмалар белән элемтә тота башлый. 16 яшендә инде ул РСДРП ның Омск оешмасының члены. Шул вакытта ук ул большевиклар оешмасына кушыла һәм гомеренең ахрынача ныклы һәм какшамаслык большевик булып, эзлекле марксист—ленинче булып кала.

Ленинче—Сталинчыда була торган иң яхшы булган барлык сыйфатларны: батырлыкны һәм ныклыкны, скромныйлыкны һәм гадилекне, дусларга карата иптәшләрчә игтибарны һәм эшчеләр сыйнфы дошманнарына карата килешмәүчәнлекне, иң кыю эшләргә ныклы омтылышны, белемгә омтылуны Куйбышевта табарга мөмкин.

Бу сыйфатлар кешеләрнең йөрәкләрен Куйбышевка тарталар, эшчеләр арасында, политик каторжаннар арасында, үзе эш алып барган урыннарда аңа авторитет тудыралар. Төрмәдә аны политик староста итеп сайлап куялар, сөргендә ул большевизмны армый-талмый пропагандалый, большевикларны туплый, аларны меньшевикларга һәм эсерларга каршы көрәшкә алып бара.

1912 нче елны Нарымда сөргендә вактында ул Беренче Май демонстрациясе оештыра һәм анда ялкынлы речь сөйли. Ул шигырьләр яза һәм бу шигырьләрендә ул революцион давылның тиздән башланачагын белдерә. Бу шигырьләр киң таралалар, аларны музыкага салалар, җыр итеп җырлыйлар.

1916 нчы ел башында Иркутск губернасы, Верхоленский өязе, Тутуры авылында сөргендә вактында Куйбышев якын тирәдәге авылларда сөргендәгеләрнең конференциясен җыя, марксистик түгәрәкләр төзи, язма журнал оештыра һәм бу журналда империалистик сугышка каршы пропаганда алып бара.

Аның подпольедәге бөтен революцион эше энергиягә тулы була. Аңа еш кына профессиясен алмаштырырга туры килә. 1905 нче елны ул хәрби медицина академиясенә кергән иде. Академияне ташлап чыгарга мәҗбүр булгач, ул трубалар заводында фрезеровщик булып эшли, пекарнядә табельче булып, кооператив артелендә бухгалтер ярдәмчесе булып хезмәт итә, чит кеше паспортлары белән яши. Массага якын булу өчен, массаны өйрәтү һәм анардан үзе өйрәнү өчен ул бернинди эштән дә чирканмый.

Куйбышев нинди генә эшкә тотынса да аны яхшы итеп эшли, ныклап, намус белән өйрәнә. Ул гүзәл атитатор кебек үк яхшы фрезеровщик та була.

⁂

1917 нче елгы февраль революциясе Куйбышевны соңгы сөргеннән азат итте, ялган паспортлардан, тикшерүләрдән һәм допрослардан, патша охранникларының эзәрлекләүләреннән азат итте.

Куйбышев иркенгә омтылды.

Гаять зур тормыш тәҗрибәсе белән, иҗтимагый үсеш законнарын практик һәм теоретик яктан белү белән коралланган Куйбышев социалистик революцияне хәзерләү буенча большевиклар партиясенең җитәкче работникларының берсе булып әверелә.

Куйбышев властьның Советларга күчүе өчен Самара эшчеләренең көрәшенә җитәкчелек итә.

Самарада меньшевикларның һәм эсерларның йогынтысы көчле була. Куйбышев меньшевикларның - эсерларның массаны алдауларын фаш итә. Бөтен властьның советларга күчүе һәм империалистик сугыштан революцион юл белән чыгу турында Ленин лозунгларын аңлата.

Куйбышев Петроградка бара, партиянең апрель конференциясендә катнаша, Ленин сөйләгәнне тыңлый һәм революцион энергиянең яңа запасы белән Самарага кайта.

Петроградта Октябрь кораллы восстаниесе җиңүенең икенче көнендә үк Самарада да Совет власты урнаштырыла. Куйбышев Самара ревкомының һәм партия губкомының беренче председателе була.

Ревком председателе постында Куйбышев бөтен кискенлеге белән эш итә. Пролетариат диктатурасы урнаштырылу моментында шулай эшләү таләп ителә дә иде. Ул, революциягә саботаж ясаучыларны һәм штрейкбрехерларны тар-мар итә, контрреволюцион буржуазиягә һәм аның булышчыларына карата рәхимсез була.

Ә аннары, Волга буенда контрреволюцион мятеж башлангач һәм Антанта котыртуы буенча җибәрелгән Чех-Словаклар корпусы ярдәме белән Самара алынгач, элекке хәрби медицина академиясе студенты, политкаторжан, фрезеровщик, икмәк пешерүче Валериан Куйбышев партиянең теләге белән стратег булып, политкомиссар булып, гражданнар сугышы полководецы булып, интервентларга һәм ак гвардеецларга каршы хәрби отпор оештыручы булып әверелә.

Ул хезмәт ияләренә ялкынлы өндәмәләр яза: „Үз властьлары өчен, социалистик революция өчен хезмәт ияләренең көрәшендә хәл иткеч момент килеп җитте. Барыгыз да коралга! Куркаклар һәм йомшак күңелллеләр хезмәтчел семьядән алып ташланырлар".

Ул Лениннең туган шәһәрендә—Сембердә, аннары Самарада Совет власты урнаштыра. IV нче армиянең Реввоенсовет члены буларак, Куйбышев Дутовка, Колчакка, Толстойга каршы һөҗүм оештыра һәм аларны тар-мар итүгә Фрунзе белән берлектә җитәкчелек итә. Аннары Куйбышев XI нче армиянең Реввоенсовет члены итеп билгеләнә, ә аннан Төркстан фронтына күчә һәм Урта Азияне ак гвардеецлардан һәм интервентлардан азат итүдә катнаша. Эмир һәм байлар яклы булганнарны тар-мар иткән һәм Көнчыгыш халыклары арасында Ленинчел - Сталинчыл дуслык нигезләрен салган куркусыз большевистик комиссар Куйбышевны Урта Азия халыклары яхшы хәтерлиләр.

***

Гражданнар сугышы бетә. Ил тыныч хәлгә күчә. Халык хуҗалыгын аякка бастырырга, кешеләрне җиарга, кадрлар хәзерләргә, Совет дәүләт аппаратын ныгытырга, партияне аңа сырышкан чит элементлардан чистартырга кирәк була. Партия Куйбышевны ныклык һәм кискенлек таләп ителә торган, большевистик партиялелек, социалистик революция эшенә чын күңелдән бирелгәнлек кирәк булган иң җаваплы постларга җибәрә.

Партиянең X нчы съездында В. В. Куйбышев Үзәк Комитет составына сайлана. 1922—1923 нче елларда ВКП(б) Үзәк Комитеты секретаре постында, ә аннары 1923—1926 нчы елларда УКК—РКИ җитәкчесе постында эшли. Куйбышев партиянең барлык дошманнарына каршы—троцкичыларга, зиновьевчыларга, контрреволюцион буржуаз милләтчеләргә каршы килешмәүчән көрәш алып бара. Ул ленинизм дошманнарын, хиянәтчеләрне фаш итә. Ул дәүләт аппаратын яхшырту һәм аны эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең ихтыяҗларына якынайту буенча гаять зур эш үткәрә.

РКИ наркомы постында эшләү Куйбышевка халык хуҗалыгының барлык тармакларын тирәнтен өйрәнергә мөмкинлек бирә. 1926 нчы елны Ф. Э. Дзержинский үлгәч, Куйбышев ВСНХ председателе итеп билгеләнә.

Бу чор социалистик промышленностьның реконструкция стадиясенә керүе чоры иде. Иптәш Сталин илне индустрияләштерү мәсьәләсен куйды. Куйбышев Сталинчыл планның энтузиасты булып әверелә һәм күп еллар буена, вакытсыз үлүенә кадәр, Совет халык хуҗалыгына социалистик реконструкция ясауның күренекле җитәкчеләреннән берсе була.

Куйбышев җитәкчелегендә беренче бишьеллыкның гаять зур планын төзүгә хәзерлек эше бара. Куйбышев Көньяк заводларына бара, кара металлургиябезнең хәлен тикшерә, булачак төзелешләрнең площадкалары белән таныша, алдынгы капиталистик илләрнең техникасын өйрәнә һәм безгә чит илдән кертергә кирәк булган җиһазларның характерын билгели.

Капитализмның троцкичы һәм уң оппортунистик реставраторларына каршы Куйбышев ныклы көрәш алып бара.

Куйбышев Совет халык хуҗалыгындагы гаять зур перспективаларны һәм мөмкинлекләрне дәрт белән ача һәм һәр вакыт промышленность төзелешенең оптималь вариантларын яклый.

1930 нчы ел ахрыннан башлап В. В. Куйбышев Госпланга җитәкчелек итә. Ул вакытта инде беренче бишьеллык планның срогыннан алда—4 елда үтәләчәгенә һичбер шик юк иде. Куйбышев партия заданиесе буенча, Сталинчыл икенче бишьеллык планны эшләргә керешә.

Партия съездларында, Советлар съездларында, инженерлар һәм техниклар җыелышларында, ударниклар җыелышларында ул һәр вакыт халык хуҗалыгы планнары турында доклад ясаучы була. Аның докладлары җентекләп эшләнгәнләр, алар совет халык хуҗалыгы белемнәренең энциклопедиясе булалар. Ул һәр вакыт күп санлы фактик мәгълүматлар китерә һәм аның речьләрендәге саннар киләчәк тормышның музыкасы булып яңгырыйлар. Бу киләчәк тормышны ул үзе реаль төстә күрә. Ул яңа һәм реконструкция ясалган заводларның илебезнең йөзен үзгәртүләрен, яңа социалистик культураның ин ерактагы караңгы почмакларга да үтеп керүен, авыл хуҗалыгын коллективлаштыруның авылдагы тормышны үзгәртүен күрә.

Партиянең XVII нче съездында Куйбышев болай диде:

„**Эпохабызның бөеклеге** Союзлар йортының калонналы залында җыелып, атларны һәм инвентарьны карауның иң яхшы ысулларын һәм методларын тикшерүче тимерчеләр һәм ат караучылар съездында; Сталинград заводының техника минимумы имтиханын тапшырган тугыз мең эшчесендә; җиңеп чыккан пролетариат тарафыннан тәрбияләнгән һәм электролит цинк заводын кыю рәвештә ходка җибәрүче яш осетин инженерда; электро-заводның кичә йорт хозяйкасы булган, ә бүген электр промышленностьның язмышы һәм перспективалары турында речь сөйләүче эшче хатын-кызда.

Эпохабызның бөеклеге—артта калган илдә социализмның җиңүен тәэмин итә алган эшчеләр сыйнфының политик яктан югары дәрәҗәдә өлгереп җиткән булуында; СССР дагы һәм чит илләрдәге вакыйгаләрне тирән игтибар белән күзәтүче, социализм төзелешенең бөтен эше өчен гаять зур җаваплылыкны иң якын рәвештә хис итүче миллионнарча эшчеләрдә һәм колхозчыларда" (В. Куйбышев. Мәкаләләр һәм речьләр, том V, бит 560).

Куйбышевның рухани көчләре чәчәк атканда үлем аны сафларыбыздан тартып алды. Ул армый-талмый эшләде. Ул Халык Комиссарлары Советы; Хезмәт һәм Оборона Советы председателенең беренче урынбасары, Совет Контроле Комиссиясенең председателе, ВКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросы члены иде. Аның эш күләмнәре һәр вакыт киңәеп торды. Үлеме алдыннан ул челюскинчыларны коткару кампаниясен бик яхшы итеп үткәрде. Бу онтылмаслык челюскинчылар эпопеясендә Куйбышев кешеләр турында никадәр игтибар һәм кайгыртучанлык күрсәтте.

Шул ук вакытта ул халык хуҗалыгы мәсьәләләре белән шөгылләнүдән дә туктамады, промышленностьның һәрбер тармагының асылына төшенә барды, кешеләрнең үсүен күзәтте, яңа планнар, социалистик дәүләтнең алга таба баруының яңа юлларын билгеләде.

Куйбышев Ленин—Сталин типындагы гаять зур политик эшлекле иде. Аның исме, аның эшләре, аның тормышы илебезнең, халкыбызның тарихында социалистик җәмгыятне иң яхшы төзүчеләрнең иң яхшыларының исемнәре белән берлектә мәңгегә сакланыр.

И. Артемьев.

РӘСЕМДӘ: „В. В. Куйбышев Самарада, труба заводында эшләгән вакытта үзенең станогы янында". Художник В. Сварога картинасы. (Куйбышев шәһәре, революция музее).

КУӘТЛЕ ХӘРӘКӘТ

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты инициативасы белән оештырылган безнең 8 кешелек бригада Белоглазов районы колхозларында ефремовчы звеноларының эш тәҗрибәсе белән танышу өчен Алтай краена барды. Без социалистик игенчелектә яңалык кертүчеләрнең — Ефремов („Искра" колхозы) һәм Чуманов („Молодая гвардия" колхозы) иптәшләрнең туган җирләрендә булдык.

Биш колхозда һәм край үзәге Барнаул шәһәрендә булу безнең барыбыз өчен дә зур мәктәп булды. Без ефремовчы звеноларның талантлы бик күп җитәкчеләре белән таныштык һәм беседалар ясадык. Безнең бригада ефремовчыларның тәҗрибәсе белән танышу өчен Алтай краена килгән бригадаларның 109 нчысы булып чыкты.

Ефремовчылык хәрәкәтенең магнәсе нәрсәдә?

Мәгълүм ки, 1936 нчы елны „Искра" колхозының звеночысы М. Е. Ефремов Себернең рәхимсез шартларында гектардан 60 центнер бодай алды. Ул вакытта бу уңыш колхозчылар өчен генә түгел, бәлки авыл хуҗалыгы белгечләренең күпчелеге өчен дә һич көтелмәгән хәл булды.

Аннан соңгы ел Ефремовка һәм аның кебек эшләүчеләргә яңа җиңү китерде. Белоглазов районының „Молодая гвардия" колхозында хата-лаборатория мөдире И. Е. Чуманов сабан бодае уңышы буенча бөтен дөнья рекорды куеп, гектардан 86 центнер алды, М. П.

Н. ШИБДИН

ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге инструкторы

Плесовских гектардан 78 центнер, И. Н. Ракитин—79,8 центнер, А. Л. Макарова—71 центнер алдылар.

Сталин күрсәткән 7—8 миллиард пот ашлык яулап алуга ирешү өчен барлык көчләрне һәм резервларны туплауга карата белоглазовчыларның чакыруына Алтай колхозчылары зур эш алып бару белән җавап бирделәр. 1938 нче ел Сталинчыл иген уңышының аңа кадәр күрелмәгән яңа рекордлары елы булды, ефремовчылык хәрәкәте чын массовый хәрәкәт булып әверелде.

Ул елны Алтай краенда 58 мең гектар чәчү мәйданында инде 4 мең 294 стахановчы звено эшләде, бу звеноларда 16 мең 500 колхозчы берләшкән иде. Звенолар гадәттәге уңышлардан 2—3 тапкыр артык иген уңышы алдылар. 1939 нчы елны крайда ефремовчы звеноларның саны 4 мең 858 гә җитте, аларда 23 мең 387 колхозчы эшләде һәм ул звенолар 148 мең гектарга якын чәчтеләр.

1939 нчы ел ефремовчылык хәрәкәтенең яңа күтәрелеше белән үтте. Колхозлар ефремовчы звенолардан ефремовчы бригадаларга күчә башладылар. Ефремовчы агротехника техник культураларга карата да тормышка кертелә башлады. Зур күләмдә булмаган һәм уңыш бирү ягыннан рекордлы булган участкылардан (тәҗрибә участкыларыннан) киң мәйданнарга күчү башланды.

Крайның атаклы ефремовчысы, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашучы А. С. Сергеева (Андреев районының Политотдел исемендәге колхозы) 46 гектардан 30 ар центнер бодай уңышы җыеп алды, ә 2 гектардан 45 әр центнер алды. Карасук районының „Память Куйбышева" колхозында звено җитәкчесе иптәш Батиенко 55 гектардан 35 әр центнер һәм 3 гектардан 60 ар центнер бодай уңышы алды. Славгород районының „Утро мая" колхозында звено җитәкчесе иптәш Черногор тәҗрибә участкысының 2 гектарыннан 475 әр пот бодай алды, ә звенога беркетелгән 51 гектарлык бөтен мәйданнан уртача һәр гектардан 183 әр пот уңыш җыеп алды.

Бик күп звенолар сабан ашлыкларының гына түгел, бәлки уҗым һәм техник культураларның да югары уңышларын алу осталыгын үзләштерделәр. Солтон районының „Майское утро" колхозында иптәш Вязьмин звеносы көз чәчкән бодайның һәр гектардан 311 әр пот алды.

Ефремовчы агротехниканың нигезләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Ефремовчылык участкыларында пар һәм туңга сөрү эшләре 20—22 сантиметр тирәнлектә иртә срокларда үткәрелә. Парга сөрелгән җирләр бөтен җәй буена кара төстә, чүпсез, чиста килеш тотыла. Кыш көннәрендә кар күп итеп тотыла, бер метр һәм аннан да калынрак була. Яз көне дым туплау (тырмалау) эше үткәрелә; аннан тыш, кар буалары ясау юлы белән, җир язгы сулар белән сугарыла. Чәчү 2—3 көн эчендә үткәрелә.

Чәчүгә орлыклар хәзерләү көздән башлана. Рекордлы участкылар өчен орлыклар, 2—3 тапкыр триерлап һәм кул белән сайлап алып, чүп үләннәре орлыкларыннан һәм башкалардан тәмам тазартылалар. Чәчүгә үзләренең үлчәүләре һәм натуралары буенча бары тик эре, тук һәм бер төрле орлыклар гына сайланып алына; аларның тишелеше кыш көне берничә тапкыр тикшерелә, ә чәчү алдыннан алар академик Лысенко методы белән яровойлаштырылалар.

Шахмат тәртибендә аркылыкыйгачлап чәчү, шулай ук киң рәтләр белән чәчү һәм тасмасыман тәртиптә чәчү киң рәвештә кулланыла. Чәчү нормаларын күтәрү, чәчү вактында орлыкларны дөрес һәм тигез күләмдә урнаштыру (1 квадрат метрга 400—700 орлык) юлы белән, чәчү мәйданындагы единицада башаклар саны арта, башакларның күләме һәм алардан алына торган орлыклар саны үсә. Шахмат тәртибендә чәчү һәрбер орлыкка туклыклы азыкны да һәм яктылыкны да чама белән тигез дәрәҗәдә алуны тәэмин итә. Чәчү материалы югары сыйфатлы булганда, җирне тирән итеп сөргәндә, орлыклар 6 дан алып 8 сантиметрга кадәр тирәнлектә урнашалар; бу хәл аларга туфракның түбәнге катлауларыннан дым килүне тәэмин итә.

Иген уҗымнарын тырмалау эшен әнә шулар, авыл хуҗалыгында яңалык кертүче ефремовчылар беренче тапкыр кулландылар. Бу чара җир өстендәге каты катлауны бетерә. Ефремовчылар җир өстендә каты катлау була башлады исә, җирне тырмалыйлар,—ягни, игеннәр тишелгән вакытта да, сабаклану алдыннан да яки сабаклану вактында да, җир өстендә каты катлау булса, җир шунда ук тырмалана.

Чәчү алдыннан кырларда 10—12 сантиметр тирәнлектә 1—2 тапкыр культивация үткәрелә. Камылны лущить итү һәм җирне предплужник белән сөрү кебек яңа агротехник чара киң рәвештә файдаланыла. Җирне ашлау өчен тирестән, черемәдән, фекалипдән, көлдән, кош һәм сарык тизгеннән, минерал ашламалардан эзлекле тәртиптә файдаланыла. Бөртекле һәм техник культураларны тукландыру эше зур күләмнәрдә үткәрелә.

Менә, мисаль өчен, Ключевский районының „Новая деревня" колхозы ефремовчысы иптәш Гулла җитәкчелегендәге хатын-кызлар звеносы тарафыннан кулланыла торган агротехниканы алып карыйк. 1938 нче елны звено 5 колхозчы хатын-кыздан гыйбарәт булган. Бу звено 4 гектар бодай һәм 1 гектар көнбагыш чәчкән. Бодай уңышы гектарыннан 22,5 центнер һәм көнбагыш уңышы гектарыннан 11,6 центнер алынган. 1939 нчы елны звенога тагын 2 колхозчы хатын-кызны кушканнар. Бу юлы звено 40 гектар күләмендәге һәм биек урындагы, элек сөрелмәгән һәм файдаланылмаган участкыны алган. Шушы участкы 1938 нче елның маенда 20—22 сантиметр тирәнлектә парга сөрелгән. Җәй көне пар басуы чиста хәлдә тотыла. Көз көне ул җирне 23 сантиметр тирәнлектә аркылыга сөргәннәр һәм ул кар астында йомшак һәм кара хәлдә калган. 1938—39 нчы еллар кышында звено валлар белән кар тоту эшен үткәргән һәм кар катлавын 1 метрга җиткергән. Бодай орлыклары элек фухтель аркылы үткәрелгән, аннан соң өч тапкыр триерланган; 4 центнер орлык кул белән сайланып алынган, шуның белән бергә, „мильтурум" дигән бодайның бер килограмында 28 меңгә кадәр эре орлык чыккан, ә „гордейформе 010" бодаеның бер килограмында эре орлыклар 18 меңгә кадәр булган. Орлыкны яровойлаштыру һәм агулау эшләрен үткәргәннәр. Кырга чыгу мөмкинлеге килеп җиту белән, иң элек кыш көне җыелган 60 центнер көлне сибеп, дым туплау эшен үткәргәннәр. Участкыны 20—22 сантиметр тирәнлектә яңадан сөргәннәр. Яңадан сөргән вакытта 6 тонна фекалип белән катлауландырылган 114 тонна тирес чыгарганнар, бер тонна минерал ашлама керткәннәр.

Чәчүне иртә срокларда үткәргәннәр. Орлыкларны бер квадрат метрга 500 орлык исәбеннән чәчкәннәр. Тишелеп чыккан орлыкларның уҗымнарын тырмалаганнар. Беренче тапкыр 20 гектар мәйданны, икенчесендә 6 гектар мәйданны тырмалаганнар. Җәй көннәрендә чәчүлекләрне 3 тап-

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

Язны тулы хәзерлек белән каршылау өчен

Буа районының „Беренче Май“ колхозы членнары, Калинин районы алдынгылары мөраҗәгатен тикшергәч, урындагы мөмкинлекләрне исәпкә алып, быел һәр гектардан 20 центнер иген уңышы алу бурычын куйдылар. Моның өчен колхозда ныклы хәзерлек алып барыла. Чәчүгә кирәкле орлыклар җитәрлек кадәр хәзерләнде һәм чистартылды. Чәчкечләргә һәм башка инвентарьларга ремонт ясау тәгәлләнде.

Кышкы агротехника чараларын үткәрү һәм җирле ашламалар җыю эшләре дә яхшы оештырылган. Бу эштә Гатият Кадыйров һәм Шакир Мәхмүтев иптәшләр көнлек норманы 200 процент үтиләр.

Колхозчылар агротехника түгәрәгендә тырышып укыйлар. Түгәрәккә 25 кеше тартылган. 8 занятие булды инде. Укуга агротехник иптәш Минһаҗов җитәкчелек итә.

Колхозда масса-аңлату эшләре яхшы куелган. Колхозчылар арасында партия һәм хөкүмәт карарларын өйрәнү, кычкырып газеталар уку үткәрелә. Стена газеталары системалы рәвештә чыгарыла.

Н. Гобәйдуллин.

Гектардан 40 центнер уңыш алырга хәзерләнәләр

„Активист“ колхозының (Норлат районы) 2 нче һәм өченче бригадалары рекордлы иген уңышы алу өчен берәр гектарлы аерым участкылар билгеләделәр. Бу участкыларның һәрберсеннән 40 центнер уңыш алу бурычы куелды. Үзләренә шушы участкылар беркетелгән звенолар моңа зур хәзерлек алып баралар. Монда чәчеләчәк орлыклар кулдан сортланалар. Орлыклар чәчкәндә 7—8 сантиметр тирәнлегендә күмдереләчәкләр. Шуңа күрә агротехник иптәш Хәялиев орлыкның шушы тирәнлектән тишелеп чыгу көчен тикшерү буенча тәҗрибә алып бара. Участкыларга кертеләчәк ашламалар хәзер.

А. Җәләй.

Ярышның башлангыч нәтиҗәләре

Һәр гектардан 100 пот иген уңышы алу өчен бара торган хәрәкәт Тымытык районы колхозларында торган саен киң урын ала. Барлык колхозлар, бригадалар социалистик ярыш договорлары төзеп, конкрет йөкләмәләр алдылар. Бу йөкләмәләрне күпчелек колхозлар намус белән үтиләр. „Эконом“, „Ишкәй“ һәм Киров исемендәге колхозлар авыл хуҗалыгы инвентарена ремонт ясауны тәгәлләделәр. Күпчелек колхозлар сортлы орлыкларны хәзерләүне тәмамладылар.

Район колхозларында 6.000 гектарда кар тотылды. Басуга 60 мең йөк тирес чыгарылды. Урындагы башка ашламаларны хәзерләү эше дә уңышлы бара. Агротехника түгәрәкләрендә 1.200 колхозчы укый.

(ТатТАСС).

КАРАРЛАР һӘМ ҮТӘЛМӘГӘН ЭШЛӘР

(Махсус хәбәрчебездән)

ВКП(б) ның Кызыл Армия район комитеты һәм район башкарма комитеты „Алга №1“, „Беренче Май“, „Большевик“, „Татарстан“, Киров һәм Ворошилов исемендәге колхозларда язгы чәчүгә хәзерлекнең барышын тикшереп, бу эштә бик күп җитешсезлекләрне ачкан иде. Тикшерү йомгаклары ВКП(б) райкомында һәм район башкарма комитетында каралды һәм һәр колхозга карата аерым карар, конкрет тәкъдимнәр кабул ителгән иде.

Шуннан соң ике айга якын вакыт үтте. Район оешмалары үзләре чыгарган карарларның тулысынча үтәлүен тәэмин итәргә, ә колхоз җитәкчеләре чәчүгә хәзерлектәге җитешсезлекләрне бетерү өчен большевистик эш оештырырга тиешләр иде. Ләкин практикада эш алай булып чыкмады. Район оешмалары да, колхоз правлениеләре дә әлеге карарлар турында оныттылар. Язгы чәчүгә хәзерлек эшендә бөтенләй дип әйтерлек үзгәреш булмады. Әйе, карарлар бар, эш юк. Мисаль өчен „Алга №1“ колхозын (председателе Мортазин) алып карыйк. Бу колхозның язгы чәчү мәйданы 2.510 гектар. Ә чәчү орлыклары җитәрлек түгел, аны булдыру турында кайгыртучы да юк. Булган орлыкларны чистарту эше дә начар бара, анализ ясау эше бөтенләй башланмаган.

Бу колхозда кышкы агротехника чараларын үткәрүгә дә җинаятьле рәвештә салкын карыйлар. План буенча каралган 1.100 гектарның бер генә гектарында да кар тотылмаган. Кырга тирес чыгару, көл һәм кош тизәге җыю планнарының уннан бер өлеше генә үтәлгән. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау эшенә җитәкчелек итүче юк. Колхозчылар арасында социалистик ярыш оештырылмаган. Колхоз председателе Мортазин күбрәк вактын кунакта йөреп үткәрә; колхоз правлениесенә өчәр-дүртәр көн килми йөри.

„Большевик“, „Беренче Май“ һәм Киров исемендәге колхозларда да шундый ук хәл. Җирле ашламалар хәзерләү эше оештырылмаган, агротехника укулары планлы рәвештә алып барылмый; югары уңыш өчен көрәштә бай тәҗрибә туплаган колхозчылар түгәрәкләргә тартылмаганнар. Киров исемендәге колхоз председателе Салахов чәчүгә хәзерлекне яхшы итеп оештыру урнына, коры вәгъдәләр бирү, мактану һәм масаю белән шөгыльләнә. Алдынгы бригадаларның, стахановчыларның уңышлы тәҗрибәләрен башкаларга күчерүне оештырмый. „Беренче Май“ колхозында (председателе Хәбибуллин) хезмәт дисциплинасын ныгытуга бөтенләй игтибар бирмиләр. Нәтиҗәдә көн саен диярлек 10—15 кеше эшкә чыкмый кала. Колхозчылар арасында политик-масса эшләре сайлаулар үткәннән соң бөтенләй тукталган.

Районда язгы чәчүгә хәзерлек эшләре башка колхозларда да гафу ителмәслек начар бара. Мәсәлән, „Восход“, „Путь Ленина“, „Активист“, „Кызыл Булат“ һәм Карл Маркс исемендәге колхозлар. Районда ремонтка кермәгән 366 сабан, 75 чәчкеч, 348 тырма, 88 культиватор бар. Чәчү орлыкларын триерлау 61 процентка, орлыкларга анализ ясау 50 процентка, кар тоту—19, басуга тирес чыгару—21, көл җыю—20 процентка гына үтәлгән.

Каргалы һәм Тат. Ялтан МТС ларында да язгы чәчүгә хәзерлек канәгатьләнерлек түгел. Каргалы МТС ында 63 тракторга, 38 культиваторга, 63 сабанга һәм башка тагылма инвентарьларга ремонт ясалырга тиеш. Ә хәзергә бары 23 кенә трактор ремонттан чыккан.

Тат. Ялтан МТС ында да 58 тракторның 15 нә генә ремонт ясалган. МТС җитәкчеләре (директоры Газизов, аның урынбасары Шәйдуллин иптәшләр) ремонт графикасын үтәү өчен кирәгенчә көрәшмиләр.

Шушы фактлардан соң бик урынлы бер сорау туа: районда язгы чәчүгә хәзерлекнең шундый хурлыклы хәлдә булуының сәбәбе нәрсәдә соң? Моның төп сәбәбе, барыннан да элек, җитәкчеләрнең үзләрендә, карарларның үтәлешен тикшермәүдә, хуҗалык эшләрен политик бурычлар белән бәйләп алып бармауда һәм колхозларга конкрет җитәкчелек итмәүдә. Район җир бүлегенең начар эшләвен аеруча күрсәтеп үтәргә кирәк. Район җир бүлеге мөдире Гатауллин, өлкән агроном Батталов иптәшләр колхозларда бик сирәк булалар. Булганда да җитешсезлекләрне тәркәп китү белән чикләнәләр.

Район оешмаларының яраксыз эш стиле әнә шундый.

К. Исламов.

АГРОТЕХНИКА УКУЫ УҢЫШЛЫ БАРА

Әтнә районының Киров исемендәге колхозында агротехника укулары уңышлы бара. Укуга 240 колхозчы тартылган. Түгәрәкләргә тәҗрибәле колхозчылардан Сәет Хәлиуллин, Дәүләт Хәлиуллин, Рәхим Әскәрев һәм Нәҗип Сөләйманов иптәшләр җитәкчелек итәләр. Дәресләр расписание буенча үткәрелә. Һәрбер түгәрәктә 7 шәр занятие булды инде. Түгәрәкләр дәреслекләр һәм күргәзмә материаллар белән тәэмин ителгән. Укулар хата - лабораториядә алып барыла. Бирәдә һәр төрле экспонатлар, үсемлекләрнең коллекцияләре, тәҗрибә ясау өчен приборлар бар.

Колхозчылар түгәрәктә алган белемнәрен практик эш белән ныгыталар. Бу колхозда кышкы агротехника чараларын үткәрү, җирле ашламалар җыю тәгәлләнеп килә. Басуга тирес чыгару планы 83 процент, торф

РӘСЕМДӘ: Автомашина идарәсенең автобаза гаражында эшләүче стахановчы шоферлардан бер төркем. Сулдан уңга—С. В. Бурмистров, М. И. Лощенников, Н. С. Сапельщев һәм Г. Ф. Сыченков иптәшләр. И. Галиев фотосы.

Фергана тәҗрибәсен республикабызның юллар төзелешенә күчерик!

СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШ БАЙРАГЫН ЮГАРЫ КҮТӘРИК

Татарстан Совнаркомы янындагы юллар төзү идарәсенең 257 нче номерлы участкысы — ул иң эре һәм җаваплы участкыларның берсе. Аның карамагына республикабызның 7 районы беркетелгән. Бу участкы карамагындагы Чкаловск тракты гына да җәй һәм көз көннәрендә һәр көнне 600—700 автомашина үткәрә. Участкы Кама елгасы тирәсенә урнашкан дистәләрчә районнарны республикабызның башкаласы Казан шәһәре белән тоташтыра һәм ул хезмәт күрсәтә торган юлның озынлыгы 200 километрдан арта.

Менә шуңа күрә дә инде Столбище районының „13 лет Октября“ артеле колхозчылары чакыруы участкы коллективына турыдан-туры кагыла һәм аның алдына конкрет таләпләр куя. Чкаловск трактының хәзергә җимерек хәлдә булган 85 километрын төзеклеккә китерү буенча булган эшнең 40 процентка якыны бу участкыда башкарылачак. Ә бу хәл участкы коллективыннан зур оешканлык күрсәтүне һәм юл төзү эшләре башлану сезонына отлично хәзерләнүне сорый.

Участкыда эшләүче юл төзү эше мастерлары, десятниклар һәм инженер-техник работниклар бу мәсьәләне 20 нче гыйнварда үзләренең кустовой җыелышларында зур активлык белән тикшерделәр. Җыелышта фикер алышуларда 13 кеше чыгып сөйләде.

— Моңа кадәр без начар эшләдек. Эшнең артта калуының төп сәбәбе масса белән йомшак эшләвебездә булды. „13 лет Октября“ артеле колхозчыларының мөраҗәгате безнең эшебездә кискен борылыш ясауга юнәлтелгән. Бу чакыруны без эшебезнең нигезенә алабыз. Масса активлыгына чын-чынлап җитәкчелек итүне ышандырабыз. Столбище районы партия һәм совет оешмаларының безгә, юл төзүчеләргә якыннан торып булышлык күрсәтүләре алда торган бурычларны уңышлы үтәп чыгуыбызга ышанычны тагын да арттыра. Бу ярдәмне без практик эш белән акларбыз, ди 6 нчы дистанция начальнигы иптәш Коноплев.

Столбище район башкарма комитетының юллар төзү бүлеге мөдире иптәш Калифатова районда масса активлыгының гаять күтәренке булуы, юл төзү дистанцияләрендә төзелеш сезонына хәзерлекнең көчәйтелүе турында сөйли.

— Без, 6 нчы дистанциядә культуралы ашханә һәм ял итү бүлмәсе оештырдык. Юл төзелешендә эшләүче колхозчылар культуралы ял итү мөмкинлеген алдылар. Якын арада без эшчеләр өчен гомуми торак төзибез. Эшкә килүче колхозчыларны тулы хәзерлек белән каршылау өчен барлык чараларны күрәчәкбез, ди ул.

Шуннан соң чыгып сөйләүче Харитонов, Кулагин, Федоренко, Шмелев һәм башка иптәшләр дә үз дистанцияләрендә эшне яңа баштан коруны, төзү материалларын ташу эшен тизләтүне ышандырдылар.

Җыелыш, социалистик ярыш байрагын югары тоткан хәлдә, төзү материалларын юлларга ташу эшен 15 нче февральгә, эш коралларын ремонтлауны 1 нче мартка тулысы белән тәгәлләү йөкләмәсен алды һәм Урдмуртия республикасының 236 нчы номерлы участкысын үзе белән тиңләшергә чакырды.

К. Б.

Хәбәрчеләр язалар

КИСКЕН БОРЫЛЫШ КИРӘК

Кама Тамагы районында зурларны укыту эшенең торышы начар, бу эш буенча инспектор иптәш Фәйзуллина эшлексезлек күрсәтә. Районда 1.109 укый-яза белмәүче һәм 1.327 аз белемлеләр бар. Боларны укыту эше алып барылмый. Мәсәлән, Олы Салтык авылында гына да 111 укый-яза белмәүче бар. Шулардан бары тик 20 генә кеше укуга тартылган. Бу авылда иптәш Фәйзуллинаның бөтенләй булганы юк.

Бу кимчелекләрне бетерүдә район мәгариф бүлеге кискен борылыш ясарга тиеш.

М. Насибуллина.

ҖАВАПСЫЗЛЫК НӘТИҖӘСЕ

Ширәмәт районы, „Ак Чишмә“ колхозының дуңгыз асыраучылык фермасында дуңгызлар өчен вактында елы урыннар хәзерләүгә әһәмият бирүче булмады. Шуның нәтиҗәсендә, хәзер дуңгызлар тышта ачык һавада торалар. Шуның аркасында, яңа туган дуңгыз балаларының үлү фактлары бар. Аларның асларындагы саламнары айлар буена алмаштырылмый. Сыер фермасында да шундый ук хәл.

Эш атларын һәм 12 баш яшь тайларны тәрбияләү эше дә начар. 2 нче бригадага 19 баш ат беркетелгән, ләкин бу атларны карау эшен 16 яшьлек бер үсмергә тапшырганнар.

Колхоз председателе иптәш Васяков бу җитешсезлекләрне бетерү турында уйлап та карамый.

Д. И.

АШХАНӘДӘ ХУҖАСЫЗЛЫК

Питрәч район үзәгендәге ашханә хезмәт ияләренең сорауларын канәгатьләндерерлек итеп оештырылмаган. Ашханә бинасы бик кечкенә, пичә яраксыз, идәне һәм стеналары җимерек хәлдә. Ашханә салкын булганлыктан, ашарга килүчеләр өс киемнәре белән утыралар.

Официанткалардан Артемьева һәм Зайцева иптәшләр клиентлар белән тупас мөгамәлә итәләр. Ашханәгә килүчеләр талон алу өчен буфет янында һәм аннан соң урын бушаганын көтеп күп кенә вакытларын әрәм үткәрәләр.

Ашханә мөдире иптәш Ершова ашханәдә тәртип булдыру һәм ашның сыйфатын яхшырту турында һич тә кайгыртмый.

Х. Хәсәнев.

ЭШ ШАРТЛАРЫ ТУДЫРЫЛМАГАН

Саба район элемтә бүлеге кышны хәзерлексез каршылады. Бинага тиешенчә ремонт үткәрелмәде, утын юк. Хезмәткәрләр өс киемнәре белән утыралар. Элемтә

кыр чүп үләннәреннән арындырганнар. Һәм чәчүлекләрне 3 тапкыр тукландырганнар. Чәчүлекләрне тукландыру эшен түбәндәгечә үткәргәннәр: беренче тапкырында 6 гектарлык мәйданда тишелеп чыккан игеннәргә 4 тонна тирес сыекчасы керткәннәр (чәчүлекнең һәрбер гектарына 1 центнер тавык тизәге, 1 центнер суперфосфат, 1 центнер кали тозы, 4 центнер көл, 4 центнер фекалий һәм 1 центнер сульфат - аммоний).

Уҗымнарның сабаклануы алдыннан бу участкыны сульфат - аммоний белән һәм суда изелгән тавык тизәге белән тагын тукландырганнар. Сульфат - аммоний белән өченче тапкыр тукландыру игеннәрнең көпшәгә утыруларына кадәр үткәрелгән. 4 мең 660 башакта сорт эчендәге орлыкландыру эшен үткәргәннәр. Звено, ефремовчы агротехниканы кулланып, „гордейформе 010“ бодаен 6 гектардан 47,5 әр центнер алган. Уртача уңыш һәрбер гектардан 20,2 шәр центнер алынган. Бу хәл корылыклы 1939 нчы елны булган!

Югары һәм ныклы иген уңышлары алу өчен көрәштә партия оешмалары зур роль уйнаганнар. Алар колхозчылар арасында киң политик - массовый эш җәеп җибәргәннәр. Коммунистлар һәр вакыт хезмәтне яңача оештыруны башлап йөрүчеләр булганнар. Партиянең Белоглазов райкомы аеруча зур уңышларга ирешкән. ВКП(б) ның XVIII нче съездында иптәш А. А. Андреев үзенең чыгышында бу райком турында сөйләгән иде.

Белоглазов районында 1936 нчы ел кышында 30 звено оештырылган булган, ләкин аларның күбесе соңыннан таралган. 1939 нчы елның язында 38 колхозның 32 сендә хезмәтне чын-чыннан звенолап оештыруга күчкәннәр. 107 ефремовчы звено эшләгән.

Партиянең Белоглазов райкомы ефремовчыларны үстерү турында армый-талмый кайгыртучанлык күрсәткән. Звено җитәкчеләре өчен 1939 нчы елны 2 тапкыр район күләмендә һәм 24 тапкыр куст күләмендә инструктив киңәшмәләр үткәрелгән, айлык курслар аркылы звеноларга 59 җитәкче хәзерләнгән. Хәзер звеноларга 64 яңа җитәкче хәзерләү эше бара. Быелгы кышта барлыгы 287 кеше агротехника курслары аркылы үтәчәк.

Ефремовчы звеноларның эше һәр вакыт район партия оешмасының игтибар үзәгендә тора. Узган ел партия райкомы, ефремовчылык хәрәкәтен тагын да үстерү белән бәйләнешле мәсьәләләрне бюро утырышларында 7 тапкыр тикшергән. Партия райкомының секретарьлары Брюзгин һәм Анташов иптәшләр звено җитәкчеләренең барсын да үзләре күреп беләләр, аларның эшләре белән көн саен кызыксыналар, аларга практик киңәшләр белән һәм күрсәтмәләр белән армый-талмый ярдәм күрсәтәләр. Районда ефремовчылар өчен 4 мәктәп оештырылган. Яңа агротехникага тракторчылар курсларында да өйрәтелә.

Агрономия һәм фән көчләре Алтай крае колхозларында югары иген уңышы алу өчен көрәшне

Чит илләрдә

Америка компартиясенең секретаре Браудерга суд процессы

НЬЮ-ЙОРК, 23 гыйнвар. (ТАСС). Маглүм ки, узган елның 23 нче октябрендә полиция АКШ (Америка Кушма Штатлары) компартиясе Үзәк Комитетының генеральный секретаре Браудерны, имештер, ул паспорт алган вакытта ялган маглүматлар биргән, дип гаепләп, кулга алган иде. Браудер кулга алынганнан соң залог хакына азат ителгән иде.

Шушы көннәрдә "Нью-Йоркта Браудерга суд процессы башланды. Бритиш Юнайтед Пресс агентлыгы, процесска карата аңлатма биреп, күрнекле җәмагат эшлеклесенә шундый тиз рәвештә булган судның АКШ тарихында әле бер вакытта да булганы юк иде, дип белдерә.

Процесста, яклаучыдан тыш, Браудер үзе речь белән чыкты. Ул, үзенә каршы куелган барлык гаепләрнең ялганга һәм формаль рәвештә бәйләнүләргә корылганлыгын күрсәтте. Ул, үзенең гүяки дөрес булмаган яки законсыз булган хәрәкәтләрен күрсәтүче бер нинди фактларны да гаепләү ягының китерә алмаганлыгын аеруча күрсәтеп үтте.

Соңыннан Браудер: „Мин коммунист булуым белән һәм компартиянең секретаре булуым белән горурланам“ дип белдерде.

Браудерга каршы куелган гаепләрнең ачыктан-ачык нигезсез булуына карамастан, суд аны гаепле дип тапты һәм 4 елга төрмәдә утыруга һәм 2 мең доллар штраф түләргә хөкем итте. Югары суд инстанцияләрендә апелляцияләр тикшерелүгә кадәр Браудер залог хакына азат ителде.

ЧЕРЧИЛЛЬНЕҢ ЧЫГЫШЫ

ЛОНДОН, 23 гыйнвар. (ТАСС). Англиянең диңгез эшләре министре Черчилль 20 нче гыйнварда радио буенча речь белән чыкты. Черчилль, диңгездәге сугышның барышы турында сөйләп, Германиянең су асты флотына каршы көрәштә Англиянең күп кенә уңышларга ирешкәнлеген аеруча күрсәтеп үтте. „Ләкин,—ди Черчилль,—без Германия тарафыннан һәр вакыт нинди дә булса яңа күңелсезлекләр көтәргә тиешбез“.

Черчилль Советлар Союзы адресына карата яла ягулы күп кенә белдерүләр белән чыкты.

Англия диңгез министренең речендә нейтраль илләргә карата янаулар үзәк урынны алып торды. Черчилль нейтраль илләрне Англия һәм Франция ягыннан сугышка катнашырга чакырды һәм, әгәр дә алар Англия—Франция блогы ягыннан чыгыш ясамасалар, аларның хәлләре „шактый начар булачак“ дигән магнәдә турыдан-туры сиздереп куйды.

ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 21 гыйнвар. (ТАСС). Гавас агентлыгы көнбатыш фронтта сугыш хәрәкәтләре турында түбәндәге белдерүне тапшыра: „Көчле салкыннар булуга карамастан, гадәттә була торган разведка һәм патруль операцияләре тукталмады. Блис елгасыннан төньяктагы районда Франция патрульләренең бер отряды, Германия гаскәрләре урнашкан җиргә—эчкәре үк кереп, Германиянең көчле отрядлары белән сугышларда үзенә юл ачу белән генә, Франция позицияләренә кире кайтып керә алды.

Германиянең күзәтү һәм фотографиягә төшерү эшләре алып барган разведка самолетлары фронт районында да, шулай ук Франциянең көнчыгыш һәм көньяк районнарында да зур активлык күрсәттеләр. Франция истребительләре Германия истребительләре белән бәрелештеләр. Шундый бәрелешләрнең берсендә немецләрнең бер самолеты бәреп төшерелде“.

Сугыш хәрәкәтләре турында кичә кич иглан ителгән рәсми белдерүдә Вогезыдан көнбатышта дошманның чыгыш ясарга омтылганлыгы һәм бу омтылышның уңышсыз тәмам булганлыгы күрсәтелә.

Бүген иртә белән иглан ителгән белдерүдә: „Фронтта үзгәреш юк“ дип хәбәр ителә.

ЛОНДОН, 22 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Франциядә Англиянең экспедиция армиясендәге хәбәрчесе, Англия солдатлары арасында күп санда салкын тиеп аурулар булганлыкны хәбәр итә.

ЛОНДОН, 21 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, кичә Төньяк диңгездә Англиянең „Гренвиль“ дигән эскадра миноносецы һәлак булган. Бу эсминец минага бәрелгән, яисә аңа Германиянең су асты көймәсе тарафыннан торпеда җибәрелгән, дип саныйлар. Эсминецның командасыннан 118 офицер һәм рядовой коткарылган, 8 кеше үлгән, хәбәрсез югалган 73 кеше һәлак булган булсалар кирәк. Коткарылганнар арасында авыр рәвештә яраланучылар күп.

„Гренвиль“ эсменец—флотилиянең лидеры. 1.485 тонна авырлыгындагы бу эсминец 1935 нче елда суга төшерелгән иде.

СУГЫШ УТЫ КАБЫЗУЧЫЛАРГА КАРШЫ ШВЕЦИЯ ЭШЧЕЛӘРЕНЕҢ ЧЫГЫШЫ

СТОКГОЛЬМ, 21 гыйнвар. (ТАСС). Реакцион элементларның Швецияне сугышка тартырга маташулары швед халкының иң киң катлаулары тарафыннан кискен рәвештә гаепләнә. Профсоюзларның бик күп түбәнге оешмалары сугыш уты кабызучыларның провокацион эшләренә каршы ачыктан-ачык чыгалар. „Дагенс нюхетер“ газетасының хәбәр итүенә караганда, Эскильстун дигән промышленность үзәгенең 7 мең эшче (металл эшчеләре) Швеция сугыш уты кабызучыларының астыртын эш алып баруларын гаепләделәр. Швеция сугыш уты кабызучылары, үзләренең империалистик хуҗаларының заданиесе буенча, Швецияне сугышка тартырга маташалар. Фрикшенде авылының профсоюз оешмасы карар кабул итте. Бу карарында ул Швециянең эшчеләр хәрәкәтенә бөтенләй чит булган интереслар өчен Швеция халкын сугышка кертергә маташучыларга каршы кискен протест белдерә. Сугыш уты кабызучыларның Швеция өчен һәм аның халкы өчен куркынычлы булган эшенә каршы протестлар дулкыны көннән-көн үсә.

АМЕРИКАДА АК ФИННӘРГӘ ЯРДӘМГӘ КАРШЫ ХӘРӘКӘТ

НЬЮ-ЙОРК, 21 гыйнвар. (ТАСС). Атаклы адвокат Манчестер АКШ та (Америка Кушма Штатларында) ак финнәргә ярдәм итү буенча реакционерлар тарафыннан алып барыла торган кампаниягә кискен рәвештә каршы чыкты. Ул, СССР ның Финляндиягә тулысынча уңайлы такдимнәр ясаганлыгын, ләкин Финляндиянең аларны кире каккалыгын аеруча күрсәтеп үтте. Манчестер, Советлар Союзының һәр вакыт тынычлык политикасын яклап чыкканлыгын күрсәтте.

„Нью-Йорк таймс“ газетасы артистларның ак финнәргә ярдәм күрсәтүгә каршы күп санда протест белдерүләре турындагы фактларны хәбәр итә. Артистлар арасында массовый протест хәрәкәте, Американың хезмәт федерациясенә керә торган театр работниклары профсоюзын махсус иглан белән чыгарга мәҗбүр итте. Бу игланда, реакционерлар тарафыннан ак Финляндия файдасына оештырыла торган „Ярдәм спектакльләрендә“ чыгарга артистлар мәҗбүр ителмәячәк, дип күрсәтелә.

НЬЮ-ЙОРК, 20 гыйнвар. (ТАСС). „Дейли Уоркер“ газетасының Тампадан (Флорида) хәбәр итүенә караганда, производство профсоюзлары конгрессына керә торган тәмәке промышленносты работникларының урындагы профсоюзы сенатор демократ Пеперга (Флорида штаты) хат җибәрде. Бу хатта ул, ак финнәргә ярдәм күрсәтү эше АКШ ны сугышка тарта дип күрсәтеп, бу ярдәмгә каршы протест белдерә.

Шул ук газетаның хәбәр итүенә караганда, „Американың студентлар союзы“ үзенең 20 нче гыйнвардагы белдерүендә ак финнәргә нинди дә булса формада ярдәм күрсәтүгә каршы чыга.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Көньяк Кытайда

Гуандун провинциясендә Кантон—Ханькоу тимер юлының көньяк участкысы секторында японнарның мең кешелек колоннасына кытайлар 18 нче гыйнварда атака ясадылар һәм аны Кантон—Самшуй тимер юлына таба кысрыклап чыгардылар.

20 нче гыйнварда кытай гаскәрләре Цзэнчэнга (Кантоннан көнчыгышта) керделәр.

Үзәк Кытайда

Хубэй провинциясенең көньяккөнчыгыш өлешендә кытайлар Янсиньгә һәм Синьтаньпуга атака ясадылар. Бу пунктлар арасындагы шоссе юлы кытайлар тарафыннан киселде.

Хубэй провинциясенең төньяккөнчыгыш өлешендә японнар 15 нче гыйнварда Суйчжоу районында кытайларның позицияләренә һөҗүм башладылар. Кытай гаскәрләре аларны чигенергә мәҗбүр иттеләр. Рәсми маглүматларга караганда 16 нчы гыйнвардан 20 нче гыйнварга кадәр бу районда японнарның 3 меңгә якын кешеләре үтерелгән һәм яраланган. Кытайлар шушы ук урында японнарның бер самолетын бәреп төшергәннәр һәм берничә танкларын ватканнар.

Аньхуэй провинциясендә гыйнвар башында кытай артиллериясе Янцзы елгасы буйлап баручы ике япон транспортын утка тоткан. Үлүчеләр һәм яраланучылар бар.

Японнар тылында хәрәкәт итүче кытай гаскәрләре Лунтань станциясенә (Нанкиннан көнчыгышта) атака ясадылар. Атака вактында японнарның 100 гә якын кешесе үтерелде.

Төньяк Кытайда

Шаньси провинциясенең көньяккөнчыгыш өлешендә Хугуаньнан көньяктарак булган районда 3 көнлек каты сугышлар нәтиҗәсендә, японнар биредә хәрәкәт итә торган 10 мең кешелек гаскәрләреннән меңнән артык кешеләрен югалтканнар. 14 һәм 15 нче гыйнварда Гаопиннан төньяк-көнчыгышта сугышлар булган. 16 нчы гыйнварда кытай гаскәрләре, өстәмә көчләр алганнан соң, японнарга каршы һөҗүм башлаганнар һәм аларны төньякка таба кысрыклаганнар. Провинциянең шушы ук өлешендә кытай гаскәрләренең аерым отрядлары Чжанцзы шәһәренең көньяк һәм көнбатыш бистәләренә якынлашканнар.

* * *

16 һәм 17 нче гыйнварда японнарның дүрт сугыш карабы Чженьхайны (Чжецзян провинциясе) тупка тоткан. 19 нчы гыйнварда японнарның 3 самолеты Нинбоның көньяк бистәләренә 24 бомба ташлаган.



Бауман районының 39 нчы номерлы мәктәбендә укучы Володя Яшин үзе ясаган самолет моделе янында.
А. Михайлов фотосы
(ТатТАСС фотохроникасы).

СПЕКУЛЯЦИЯГӘ КАРШЫ РӘХИМСЕЗ КӨРӘШЕРГӘ

Спекуляция эксплоатациянең бер төре. Совет власты спекуляциягә каршы һәр вакыт кискен көрәш алып барды һәм барачак. Ләкин спекулянтлар, социалистик милекне урлаучы караклар шайкалары үзләренең хиянәтчел методларын торган саен үзгәртә баралар. Алар социалистик промышленность белән потребитель арасына кереп, хезмәт ияләрен киң куллану товарлары белән тәэмин итү эшендә өзеклек тудырырга маташалар.

Икмәк һәм башка төрле товарларны спекуляция ясау теләге белән җыеп ятучылар турында Татарстанның милиция органнары соңгы вакытларда бик күп кенә фактларны ачтылар һәм гаепләнүчеләрнең эшләрен тикшерү органнарына тапшырдылар. Тентү вактында алардан бик күп азык продуктлары—он, ярма, икмәк һәм башка төрле товарлар табылды.

Мәсәлән, 19 нчы гыйнварда ерак Усиядәге 6 нчы номерлы магазинда эшләүче Сагдиев Барый һәм Сагдиев Билал дигән кешеләр җинаят өстендә тотылдылар. Алар магазинга кайтарылган азык товарларын урлау белән шөгыльләнгәннәр. Тентү вактында аларның квартирасыннан 22 пот бодай оны, 40 пот арыш оны, 100 пот бәрәңге, 47 кисәк кер сабыны, 828 кап шырпы, 40 килограмм май, 15 килограмм кара борыч, 8 данә суйган каз һәм башка төрле бик күп продуктлар табылды. Сагдиевлар кулга алындылар.

Шушы көннәрдә Киров райпищеторгының 19 нчы куст директоры Николаев магазинда сату өчен кайтарылган 3 капчык ярма һәм 13 мичкә варенье урлап тотылды.

Буа районы гражданы Бикмөхәметов Нафик күп вакытлардан бирле он белән спекуляция ясап килгән. Бикмөхәметов күптән түгел кулга алынды. Тентү вактында аның өеннән 2.400 килограмм он табылды.

Кайбыч районы гражданнары Варламов, Александров, Батурин һәм Исаевлар Зеленодольский шәһәрендәге магазиннардан пешкән икмәк һәм он җыеп йөргән вакытта тотылдылар. Алардан 440 килограмм пешкән икмәк һәм 115 килограмм он табылды.

Мамадыш районы гражданнары Шкунов һәм Гестеровлар он белән спекуляция ясауда гаепләнеп, кулга алындылар. Тентү вактында аларның квартирасыннан 34 пот бодай оны һәм 29 пот арыш оны табылды.

12 нче гыйнварда Кызыл Йолдоз районы, Кадрәк авылы гражданнары Артемьев һәм Мельниковлар пешкән икмәк төяп китеп барган вакытта милиция органнары тарафыннан тотылдылар. Аларның йөгеннән 200 килограммнан артык пешкән икмәк табылды. Артемьев һәм Мельников җаваплыка тартылдылар.

Трансторгпитның 7 нче номерлы икмәк магазинында эшләүче Галимҗанов магазинга икмәк ташучы Фролов дигән кешегә 6 нчы гыйнвар көнне бер юлы 70 килограмм икмәк саткан. Фролов бу икмәкләрне кыйммәт бәя белән квартирасыннан сатып яткан.

Югарыда күрсәтелеп үткән кайбер фактлар күп нәрсә турында сөйлиләр һәм спекулянтларга каршы көрәшне тагын да көчәйтүне сорыйлар.

Совет сәүдәсе эшендә өзеклек тудырырга маташучы спекулянтларны, жуликларны тамырыннан йолкып ташларга кирәк. Бу эштә җәмагатчелек милиция органнарына зур булышлык күрсәтергә тиеш.

Н. Тихонов.

Татарстан милиция идарәсенең өлкән лейтенанты.

Стена газеталары редколлегияләре составын тикшерү

Партиянең Теләче райкомы районда чыга торган стена газеталары редколлегияләренең составын тикшерүне оештырды. Моның өчен урыннарга 40 кеше чыгып китте.

Стена газетасы редакторлары һәм актив хәбәрчеләр хәзер район газетасы янында практика үтәләр. Гыйнвар ахырларында стена газетасы редакторларының авыл хәбәрчеләре белән берлектә район күләмендә киңәшмәсе үткәреләчәк.

БЕЛДЕРҮ

Бүген, кич сәгат 7 дә, Дәүләт университетының актовый залында Молотов районы өчен „Дошманнарга каршы көрәш—партиянең үсеш законы“ дигән темада лекция була. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ның 12 нче бүлеге буенча). Лектор иптәш Громов.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Почтамтның администрациясе, профсоюз оешмасы һәм бөтен коллективы почтамт работнигы, Шәһәр Советы депутаты
Разия Хәбибулла кызы ГАЗИЗОВА
ның вакытсыз үлүен тирән кайгы белән белдерәләр һәм аның семьясенең кайгысын уртаклашалар. 1—1

ГОРЗДРАВ
1940 нчы елда теш протезлау буенча лимитлар билгеләү өчен, профсоюз өлкә комитетлары ның, ул профсоюзга нинди учреждениеләр һәм предприятиеләр керүен күрсәтеп, үзләрендә учетта торучы профсоюз членнарының саны турында, шушы ел, 27 нче гыйнвардан да соңга калмыйча, түбәндәге адрес буенча маглүмат бирүләрен сорый: Черных шевский урамы, 2, дүртенче кат, 106 нчы бүлмә.

Н. Александров исемендәге типографиядә кислотадан бушаган, 38 литр сыешлы **БУТЫЛЬЛӘР** (зур шешәләр) **САТЫЛА**
Бауман урамы, Матбугат йорты, Телефон 24—82. 2—1

Игтибар итегез!
Главмясосбытның Татарстан конторасы карамагындагы
ЗАКУСОЧНАЯ
иттән хәзерләнгән һәр төрле порцияле кайнар ашлар, шулай ук, күбәйтелгән порцияле ПИЛЬМӘННӘР һәм СОЛЯНКАЛАР хәзерли. Килүчеләргә хезмәт күрсәтүдән тыш, ашлар чикләнмәгән күләмдә өйгә дә җибәрелә. Ашлар югары сыйфатлы продукциядән хәзерләнә һәм бәяләре дә югары түгел.
Адрес: Бауман урамы, 33. 2495—3—3

Татар Дәүләт Опера театры
(Зур Драма театры бинасында. Телефоннар: 5—20 һәм 30—78),
25 нче гыйнварда
ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ
Балет 3 пәрдәдә. Талон 66.
Кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ЗДТ кассасында сатыла.
Культпоходлар оештыру буенча заявкалар алына.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
25 һәм 26 нчы гыйнварда
КЫЮ КЫЗЛАР
Талоннар: бүген 103, иртәгә 104.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
26, 27 һәм 28 нче гыйнварда
МАСКАРАД
Талоннар: 26 нчы гыйнварда 84, 27 нче гыйнварда 85.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн
Москва 4 нче труппасының гастрольләре
ИНТЕРМЕДИЯ
ЧИК ЙОЗАКТА
Кич 8 дә башлана.
АНОНС: РСФСР ның атказанган артисты орденлы
ЗОЛЛО гастрольләре
Атнаның икенче көнендә цирк эшләми.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„УНИОН“ 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8 һәм 10 да	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	УКЫТУЧЫ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез МИТЬКА ЛЕЛЮК Кич УКЫТУЧЫ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	ДОКТОР КОЛЮЖНЫЙ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	Степан Разин

КИРӘК:
Бондюг заводына, баш энергетик хезмәтләрен үтәү өчен, ПРАКТИК ЭШ СТАЖЛЫ ИНЖЕНЕР - ЭНЕРГЕТИК. Гариза белән бергә белгеч үзенең белгечлеге буенча эш стажы турында белешмә бирергә тиеш. Татарстан АССР, Бондюг заводы, кадрлар бүлеге. 124—3—1

„Химзаготлес“ трестының агач материаллары хәзерләү буенча өлкәара Казан конторасына, ашыгыч рәвештә, контора аппаратында эшләү өчен ӨЛКӘН РЕВИЗОР, Мари АССР һәм Киров өлкәсе районнарында эшләү өчен ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР УРЫНБАСАРЛАРЫ һәм БУХГАЛТЕРЛАР. Казан, Кызыл Армия бистәсе, Зур урам, 62. Баш бухгалтерга килергә. Телефон 42—06. 92—3—3

ЗАКАЗ № 329.